ФӘРИТ МӨХӘММӘТШИН: «Сезнең тырышлыгыгыз белән менә шундый уңышлы республикада яшибез!» > 2

АПРЕЛЬ ҮЗГӘРЕШЛӘРЕ Россия законнарына кертеләчәк үзгәрешләрнең иң мөһимнәре > 2

ҮКЕНЕЧ «Үзе исән чакта мин аңа беркайчан да «Әнием» дип тә, «Әникәем» дип тә әйтмәдем» > 4

БАЛА ХАКЫ Алимент турында төп сорауларга белгеч ачыклык кертә > 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 46 (28819) | Шимбә | 2 апрель | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

КӨТЕЛГӘН ШАТЛЫК

КАЗАННЫҢ ҖӘМИГЪ МӘЧЕТЕНЕҢ УРЫНЫ ҺӘМ КАЙЧАН ТӨЗЕЛӘСЕ БИЛГЕЛЕ

Вакыйга

Апрельдә эскизы сызыла, майда ташы салына, көзгә төзелеш башлана. Ниһаять, Татарстан башкаласының да үз Җәмигъ мәчете булачак. Бу зур төзелеш эшен кабат бергә һәм бердәм рухта башкарып чыгарга ниятлиләр. Татарстанның андый зур корылмаларны бергәләп торгызу тәҗрибәсе бар инде.



Илдар Мөхәммәтҗанов

Яңа мәчет «Кырлай» паркы урынында төзеләчәк. Хәзер паркта аттракционнарны сүтү, мәйданны бушату эшләре бара. Бу эшләрне май аена кадәр бетерергә ниятлиләр.

Халык хәл итте

Татарстан башкаласына бу мәчет кирәкме-юкмы дип урынсыз уйлануларны онытыр чак. Татарстан Президенты Аппараты җитәкчесе Шамил Гафаров әйтүенчә, мәчет төзелеше мәсьәләсе кичә-бүген генә күтәрелмәде. «Мөрәҗәгатьләр күп булды. Шул исәптән башка дин вәкилләреннән дә. Татарстан Президенты башкалада мәчет төзү турында карар кабул итте. Бу тәкъдим Идел буе Болгар дәүләтендә ислам динен рәсми рәвештә кабул итүнең 1100 еллыгын билгеләп үтү чараларының федераль исемлегенә керде», – диде ул.

Яңа мәчет төзү өчен бюджет акчасы файдаланылмаячак. Бу эшне тулысынча «Игелек» фонды һәм битараф булмаган кешеләр маясына башкарып чыгарга ниятләнә.

Мәчетнең төгәл мәйданы проект эше расланганнан соң билгеләнәчәк. Гыйбадәт урыны төзелгәч, якын-тирә урыннарны яшелләндерү-ямьләндерү эшләре башкарылачак, машина кую урыны мәсьәләсе хәл ителәчәк. Киләчәктә Җәмигъ мәчетенә исем бирүне дә күздә тоталар. Анысын тавыш бирү юлы белән халык хәл итәчәк. Мәчет нигезенә беренче ташны 20 майда салырга җыеналар, ә төзелеш эшләре бу елның көзендә башланачак.

Казан башкарма комитеты җитәкчесе Рөстәм Гафаров парксыз калдык инде дип борчылучыларны тынычландырды. «Яңа аттракцион паркы мәсьәләсе өйрәнелә, Казан парксыз калмас. Ә мәчет – башкаланың яңа символы һәм ул бөтен дөнья өчен Казанны гәүдәләндерә торган корылмага әйләнер дип ышанам», – диде Рөстәм Гафаров.

Ислам дөньясына капка

Казандагы яңа мәчет 10 мең кешене сыйдырачак. Кем өчендер, бәлки, бу сан зур булып тоелыр. Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин исә моның әле чик түгеллеген чагыштыруда дәлилләде.

– Россия эчендәге мәчетләр мисалында карыйк. Мәскәүдәгесе 10 мең кешене сыйдыра. «Чечня йөрәге» шулай ук. Махачкаладагысы 15 меңләп кешегә исәпләнгән. Анда хәзер тагын бер үзәк төзелә, анысында 50 мең кеше гыйбадәт кыла алачак. Шуңа күрә 10 мең дигән сан берәүне дә куркытырга тиеш түгел. Бу – замана таләбе, табигый хәл. Барыбыз да беләбез: Казан – илебездәге ислам үсешенә юнәлеш бирә торган шәһәр, ул мөселман дөньясының Төньяк башкаласы дигән исемен хаклы рәвештә йөртә. Казан – Россиянең ислам дөньясына капкасы, – диде мөфти. – Бәйрәм көннәрендә күпләп җыелу урыны, зур мәчет кирәк иде. Мәчет – дога урыны гына түгел. Биредә рухи-әхлакый чаралар да күп уза. Мәчетнең үзәктә булуы, минемчә, уңайлы. Ул барыбызны да берләштерүче урын булырга тиеш.

Җиңүчегә – миллион

Мәчетнең нинди буласы әле билгеле түгел. Әмма аның республика һәм башкала архитектурасына, милли рухыбызга туры килергә тиешлеге көн кебек ачык. Моннан тыш гыйбадәт урынының башка архитектура үрнәкләре белән ярашып, гүзәл ансамбль булып торуы мөһим.

1 апрельдән Җәмигъ мәчете эскизына халыкара бәйге игълан ителде. Җиңүчеләрне акчалата бүләк көтә. «Игелек» республика фонды башкарма директоры Илнур Рәхимов конкурста катнашу таләпләрен аңлатты.

Бәйге халыкара дәрәҗәдә узгач, Россия һәм башка ил вәкилләре дә катнашыр дип көтәләр. Гаризаны 15 апрельгә кадәр тапшырырга мөмкин. Конкурс ике этапта узачак. Гаризалар кабул ителгәннән соң, икенче этапка 6 катнашучы үтәчәк, аларның проектлары белән танышу каралган. Финалга исә өч кеше йә команда чыгачак.

– Беренче урынга – 2,5 млн, икенче урынга – 1 млн, өченче урынга исә 500 мең сум күләмдә акча биреләчәк, – диде Илнур Рәхимов. – Конкурсның жюри әгъзалары арасында танылган архитекторлар, хакимият, фән вәкилләре, дин әһелләре булачак. Бәйгенең нәтиҗәләрен 3 айдан соң игълан итәчәкбез.

Илнур Рәхимов сүзләренчә, конкурсантлар өчен кыса-таләпләр куелмаган. Мәчетне ничек итеп күзаллауларын ачыклау өчен фантазия ирекe биреләчәк, кыскасы.

Катлаулы сәяси-икътисади вазгыять шартларында мондый зур төзелешләргә алыну дөресме? Шундый шикләр дә ишетелә, әлбәттә. Шамил Гафаров сүзләре белән әйтсәк, мәчет бер елга гына һәм көн саен төзелә торган корылма түгел. Ул әле киләчәк өчен дә кирәк. Шуның белән мөһим дә ул. Мәчетне мөмкин булганча кыска вакыт аралыгында төзеп бетерү турында хыялланалар.

– Халык фикереннән башка төзелә, халык фикереннән башка гына исем бирелә торган урын түгел бу. Андый зур төзелешләрне ике-өч кеше йә белгечләр советы җыеп кына башкарып чыгып булмый. Мәчетне бакча башына салып булмый. Ул иң матур урында булырга тиеш. Мәчет төзелеше дөньядагы хәлдән түгел, халык теләгеннән тора. Аны булдыру карары да халык ихтыяҗыннан чыгып кабул ителде. Ничек дөрес булмасын? Дөрес, аклана торган юл бу. Җәмигъ мәчете бездә булырга тиеш! Без генә түгел, аны бергә төзибез.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

Өлкәннәрне тикшерәләр

«Демография» илкүләм проекты кысасында быел 56 мең өлкән яшьтәге кеше медицина күзәтүе узачак. Бу хакта «Объясняем. Республика Татарстан» сайтында узган туры эфир вакытында Татарстанның Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының бүлек мөдире Анжелика Вәлиева хәбәр итте.

«Демография» илкүләм проекты кысасында тормышка ашырылучы «Өлкән буын» проекты ярдәме белән без 2019 елда 43 автомобиль сатып алдык. Ул машиналар авыл җирләрендә яшәүче өлкәннәрне район хастаханәләренә табибка күренергә һәм диспансеризация үтәргә йөртеп тора. Әлеге хезмәт 65 яшьтән өлкәнрәкләргә күрсәтелә», – диде ул.

Быел олы яшьтәге 56,5 мең кеше диспансеризация узачак. Бүгенгә аларның 14 меңе тикшерәнә, 6 меңнән артыгы диспансеризацияне үтеп бетергән инде.

Туристлар поездны сайлый

Казан апрель аена поездларга иң күп билет сатылган 20 шәһәр исемлегенә кергән. «Туту.ру» сәфәрләр сервисы аналитик үзәгендә, 1 апрельдән 30 апрельгә кадәр сәяхәт итү өчен 1–29 март аралыгында алынган билетларны өйрәнеп, шундый нәтиҗә ясаганнар. Казанга поездда утырып килү бәясе бер кешегә уртача 2896 сум (бер якка) тәшкил итә. Апрель ае өчен тимер юл транспортына билет алган пассажирларның 1,9 проценты Татарстан башкаласына туры килә. Казанга Мәскәүдән, Екатеринбург, Пермь, Санкт-Петербург һәм Волгоградтан туристлар күбрәк агыла.

Сүз уңаеннан, 1 июньнән яшьләр һәм студентлар туризмы программасы старт ала. Яшьләргә ул югары уку йортларының тулай торакларында тукталып, ил буенча арзанлы бәядән сәфәр кылу мөмкинлеге бирә. Быел проектта Россиянең 98 шәһәреннән 155 вуз катнаша.

Рамазан – изге эшләр ае

Рамазан аеның беренче көнендә, гадәттәгечә, изге эшләр хәйрия марафоны башланды. Акцияне һәр ел саен Диния нәзарәте авыру балаларга, аз керемле гаиләләр һәм мохтаҗларга булышу йөзеннән үткәрә. Нәзарәтнең «Зәкят» хәйрия фонды мондыйларны азык-төлек белән тәэмин итәчәк, ифтар мәҗлесләре үткәрәчәк, аларга фитыр сәдакасы, фидия һәм зәкят өләшәчәк.

Узган елда «Рамазан – изге эшләр ае» акциясе кысасында 21 балага ярдәм күрсәтелгән. Шулай ук Казанның 807 аз керемле гаиләсенә азык-төлек тупланмалары тапшырылган.

Быел «Зәкят» хәйрия фонды мохтаҗ гаиләләрдән 20 баланы дәвалауга акча җыеп бирүне күздә тота.

dumrt.ru

Язгы ярминкәләр гөрли

Бүген Казанда язгы авыл хуҗалыгы ярминкәсе уздырыла. Сәүдә иртәнге алтыдан көндезге уникегә кадәр шәһәрнең барлык җиде районында 15 мәйданчыкта алып барыла. Ярминкәдә районнар фермерлары һәм агрохолдинглар катнаша. Анда арзанрак бәядән ярма, он, ит, балык, шикәр комы, яшелчә һ.б. сатып алырга мөмкин.

«Салават күпере» торак комплексында яшәүчеләр өчен язгы ярминкә Осиново бистәсенең «Радужный» сәүдә үзәге машина кую урынында үткәрелә.

Көн кадагында

Берсе булмаса, икенчесе бар

Дару җитәчәк! Соңгы арада белгечләр тарафыннан бу сүзне еш ишетергә туры килә. Журналистлар белән чираттагы очрашу барышында да «Таттехмедфарм» оешмасы җитәкчесенең дарулар белән тәэмин итү буенча урынбасары Надия Шемякина шулай дип тынычландырырга ашыкты.

Белгеч сүзләренә караганда, халык әле дә булса запаска күпләп дару җыюын дәвам итә. «Ажиотаж дәрәҗәсендәге сорау – безнең өчен күптән гадәти хәл. Ул ел да кабатланып тора. Бакча чоры, җәйге ял вакыты җитүгә, кеше күпләп дару җыя башлый. Яз-көз вируслы авырулар котырган чорда да даруларга сорау бермә-бер арта. Авырып терелгәннән соң кеше, гадәттә, якыннары өчен дип дару алып куя», – ди белгеч. Шуңа күрә соңгы арада даруханәләрдә күзәтелгән хәлләргә дә әллә ни аптырамый ул. Пандемия чорында да шундый ук хәл күзәтелде. Халык, чирдән саклану өчен, күпләп битлек, пирчәткә, антисептик чаралар сатып алды.

Соңгы арада күпләр даруханәләрдә калкансыман биз авыруы вакытында кулланылган «L-Тироксин» даруын табып булмый дип зарлана. Надия Шемякина моны һаман да шул, шикәр комы кебек үк, кирәксә-кирәкмәсә, кабы-кабы белән запаска дару җыю нәтиҗәсе дип бәяли. Бу сүзләрнең хаклыгына инану өчен рәсми саннарга күз салу да җитә. Әйтик, 2019 елда ил күләмендә – 11 миллион кап, 2020 елда 26 миллион кап сатылган булса, мартның беренче ун көнендә үк инде бу сан 3,6 миллион капка җиткән. «Юкса һәр ун көн саен аның кадәр дару кирәк булмаячагы көн кебек ачык бит инде», – ди Надия Шемякина. Белгеч сүзләренә караганда, якын арада бу дару барлык даруханәләргә дә кайтачак. Температураны төшерә торган «Нурофен» даруын таба алмыйча йөрүчеләрне дә шулай дип тынычландырды ул.

Хәтерләсәгез, күптән түгел Татарстанның сәламәтлек саклау министры урынбасары Фәридә Яркәева да халыкны запаска дару җыймаска өндәгән иде. Күбрәк инсулинсыз калмаммы дип борчылган кешеләргә атап әйтте ул бу сүзне. «Инсулинга кытлык булмаячак. Аны күпләп алып куюдан файда юк. Күпләр инсулинны суыткыч ишегендә саклый. Ләкин аны суыткычның үзендә сакларга кирәк. Әмма ничек кенә дөрес сакласаң да, аның да яраклылык вакыты бар», – дип сөйләде министр урынбасары журналистлар белән очрашуда.

Белгеч сүзләренә караганда, дөрес сакламаган очракта, яраклылык вакыты чыкмаган даруның да шифасы тимәскә мөмкин. «Аш бүлмәсендә температура тотрыклы түгел. Шуңа күрә анда даруларны, гомумән, сакларга ярамый. Аларны тәрәзә төбендә, кояш төшә торган ачык урыннарда да тотмау хәерле. Дөрес сакламаган очракта аларның файдасы калмый. Юкка гына даруханәләрдә һәр дару аерым шартларда сакланмый бит инде», – ди Фәридә Яркәева.

Бүген күпләр Россиядә җитештерелгән даруларга сагаеп карый. Аларның файдасы юк, булса да, аз, дигәнрәк фикер яши. Надия Шемякина моны ялгыш фикер дип саный. Ник дигәндә, бүген дөнья күләмендә бөтен илләр дару җитештерү өчен кирәкле чималны Кытай белән Һиндстаннан ала. Шул рәвешле даруларны барысы да бер үк төрле җитештерә булып чыга. Димәк, аларның организмга шифасы да бер үк дәрәҗәдә.

Ахыры 2 нче биттә >

Сүзгә-сүз

Татьяна БУЦКАЯ, Россия Дәүләт Думасының гаилә, хатын-кызлар һәм балалар мәсьәләләре буенча комитет рәисенең беренче урынбасары:

Ана капиталының бер өлешен акчалата алу мөмкинлеген булдырырга кирәк. Әйтик, декабрьдә әти-әни, әлеге акчаны торак сатып алуга тотам дип, гариза язган ди. Ә киләсе ел башында ана капиталын индексацияләгәннәр, нәтиҗәдә акчаның бер өлеше тотылмыйча калган. Суммасы 25 мең сумнан артык түгел, тик аны бернигә дә сарыф итеп булмый. Хисап палатасы мәгълүматлары буенча, сигез йөз мең кешенең акчасы шулай калган.

(«Парламентская газета»)

РОССИЯДӘ – МӘГЪЛҮМАТ ЧЫГАНАГЫ

Ил халкы традицион мәгълүмат чараларын күбрәк күзәтә башлаган. Иҗтимагый фикер фонды Россиядә яшәүчеләр арасында үткәргән сораштыру нәтиҗәсе шуны сөйли.

ЯҢАЛЫКЛАРНЫ КАЙДАН БЕЛӘСЕЗ?

39% традицион мәгълүмат чараларыннан (газета, телевидение, радио)

29% интернеттан

ҖИДЕНЧЕ КАТТАН КАРАШ

Наил ШӘРИФУЛЛИН

Хокуклар, салымнар һәм алгарыш

Күпләр: «Илебез Европа Советыннан чыкты, аның хокукый актлары хәзер инде биредә үтәлмәячәк», – дип уйласа да, алай ук түгел. «Кеше хокуклары буенча Европа конвенциясе» дип аталган документ тәгаен үтәләчәк. Сәбәбе дә гади: аның төп параграфлары Россия Конституциясенең II бүлегендә (17–64 маддәләр) тулысынча диярлек урын алган. Шушы хәл үзе генә дә безне хокукый дәүләт итә һәм цивилизацияле илләр арасында калдыра.

Җиде дистә елдан артык тарихы булган данлыклы Конвенциянең Россиядә ратификация үтүенә бу атнада 24 ел тулды. Конвенция кеше хокук һәм ирекләренең кагылгысызлыгын билгеләп кенә калмый, һәр дәүләт үз гражданына аларны гарантияләргә тиешлекне дә ассызыклый. Башкача әйткәндә, документ «Дәүләт – кеше өченме, әллә инде кеше – дәүләт, аның мәнфәгатьләре өченме?» дигән сорауга «Дәүләт – кеше өчен, аның лаеклы яшәеше, тормыш-көнкүреше өчен», – дип җавап бирә. Гәрчә әлеге формула Конвенцияне үз иткән дәүләтләрнең һәммәсендә тулысынча тормышка ашырылмаса да.

Кем кемгә тиеш: дәүләт безгәме, без дәүләткәме? Бу сорау, ихтимал, беренче дәүләтләр оешуга ук яралгандыр. Халыкларның дәүләткә берләшүе нигезендә күмәкләшеп каршы тору – яу белән килеп, талап, үтереп китүче чит-ят кавемнәрдән бергәләп саклану ихтыяҗлары яткан, дип фаразлау дөрес кебек. Гаскәр, армия булдыру, аны һәм дәүләт хезмәтендәгеләрне асрау өчен халыктан салым җыю да дәүләт белән бергә яралган. Тик беренче дәүләтләр барлыкка килүгә үк, аның башында торучылар власть дигән майлы калҗаның татлылыгын, хакимлекне шәхси ихтыяҗларда да яхшы файдаланып булуын сизгән, дияргә дә нигез бар. Халыктагы таркаулыкны да алар күргән. Бәс шулай икән, нигә әле гавамны тулысы белән дәүләткә баш идермәскә дә, нигә саумаска, хакимияткә һәм аның башында торган затларга, югары чиновникларга хезмәт иттермәскә, югарыдагыларны рәхәттә яшәтмәскә? Һәм яшәткән дә. Андый традиция күп гасырлар буе килгән һәм әле дә юкка чыгарга ашыкмый.

Салымнарны гына алыйк. Гражданнан аны каералар, тик ул акчаның кая киткәнлеге турында исәп-хисап тоту юк дәрәҗәсендә. Хәер, аны сораучы да юк. Ә бит салым ул – дәүләт күрсәткән хезмәтләр өчен түләү. Син сайлап куйган дәүләт органнары сиңа хезмәт күрсәтә, син түлисең. Биредә һәр тиен, һәр сум исәптә булырга тиеш. Демократик илләр шуның өчен дә демократик – гражданнар аның ишене белә, аңлый.

Демократия барып җитмәгән, гражданлык җәмгыяте оешмаган тарафларда, авторитар, тоталитар илләрдә исә салым түләүне халык ясак түләү кебегрәк кабул итә. Телисеңме, теләмисеңме, керемеңнең бер өлешен син дәүләткә биреп барырга тиеш. Физик заттан аны сорап та тормыйлар. Хезмәт хакын алганда, салым инде тотып калынган була. Юридик зат салым түләмәгән очракта Җинаять кодексында маддә бар, түләми кара. Шунысы аяныч: бәндә салым түләп торса да, дәүләттән яклау, ярдәм бик көтми. Ул аңа өйрәнмәгән, белми. Хокуклар дигәндә дә, яхшы тормыш шартлары дигәндә дә ул күбрәк үзенә ышана. Нәкъ шул сәбәпле, хокукый булмаган дәүләттә «салым түләүче» сүзе горур яңгырамый. Киресенчә, керемне яшереп, салымны мөмкин кадәр азрак түләү егетлек санала. Әле «Дәүләтнекен күпме генә алма, урлама – үзеңә тиешне кайтара алмыйсың», – дип тә җибәрәләр. Бары чын хокукый дәүләттә генә салым түләмәү, дәүләтне кәкре каенга терәтергә маташу хурлык санала.

Хокуклар һәм алгарыш. «Кеше – дәүләт өчен» булган илләр көндәшлектә «Дәүләт – кеше өчен» шигаре белән яшәгән илләргә һәрдаим оттыра. Чөнки беренчеләрендә кеше үсәр, камилләшер өчен шартлар юк яисә җитешми. «Кеше капиталы» дигән иң затлы капитал яралып, формалашып бетә алмый аларда. Алгарыш, үсеш шуңа күрә аксый. Атны кызулатам дип, кемдер, тезгенне бушатасы урында, аңа авызлык кидерә дә дилбегәне тарткалый башлый. Бу – артталык сәбәпләрен күрмичә, алардан котылырга тырышмыйча, нәтиҗәләр белән көрәшү дигән сүз түгелме? Шулай кебек. Ягъни бер Нобель премиясе лауреаты әйткәнчә: «Үсеш-алгарышка кеше хокукларын яклап түгел, ә технологияләр һәм көчләү юлы белән ирешеп була, дигән иллюзия белән яшәү». Иллюзия авторлары мисалга Кытайны, ул ирешкән уңышларны китерә. Тик алар ул илнең меңләгән исемдәге товар җитештерүче зур завод булган җәһәттә дә читтән кергән технологияләрне файдалануын күрми. Кытайда җыелган, мин бу юлларны сырлап утырган Asus компьютеры, мәсәлән, Тайвань, кичә кич хоккей караган Samsung телевизоры Көньяк Корея лицензиясе, ягъни технологияләре буенча эшләнгән. Кытайның плагиат белән шөгыльләнүе, технологияләрне сатып алу гына түгел, урлавы күпләргә мәгълүм.

Урлап җыелган мал – гөнаһлы мал. Дәүләтнең кешегә хезмәт итмәве сәбәпле яралган коррупция, караклык та билгеле бер катлауны гына баета. Илдәге халыкның интеллектуаль потенциалын тулысынча эшкә җиккәндә, социаль лифтлар камил эшләгәндә, яхшы белгечләр читкә китмәгәндә генә фәнне һәм технологияләрне үстерү мөмкин. Алгарышка, муллыкка ирешү мөмкин. Кеше хокуклары тулысынча якланмаган ил техник казанышларны гомере буе импортларга мәҗбүр. Чөнки ирекле, инициативалы, гыйлемле затлар гына яңалыклар тудырырга сәләтле.

КӨТЕЛГӘН ҺӘМ КӨТЕЛМӘГӘН БҮЛӘК

«Сөенечтән елап ук җибәрдек», «бик дулкынланабыз», «төн буе йоклый алмадык». Кремльдә Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин кулыннан дәүләт бүләкләре алган кешеләр менә шундый хисләр кичергән. Алар арасында фән, мәдәният, медицина, сәнгать өлкәсендә эшләүчеләр генә түгел, маңгай тирләрен түккән җир кешеләре дә бар.

tatarstan.ru

– Безнең казанышлар сезнең ярдәм белән булдырылды. Татарстан Президенты Рөстәм Нургали улы Миңнеханов һәм бөтен халкыбыз исеменнән республиканың социаль-икътисади үсешен ныгытуга зур өлеш керткәнегез өчен рәхмәтемне белдерәм. Сез – безнең горурлыгыбыз. Үзегезнең намуслы хезмәтегез, Ватаныбыз язмышына битараф булмавыгыз белән яшь буын һәм республикабыз халкы өчен үрнәк булып торасыз, – диде Фәрит Мөхәммәтшин.

Фәрит Мөхәммәтшин нәкъ менә шундый алдынгы татарстанлылар хезмәте нәтиҗәсендә республиканың күп кенә күрсәткечләр буенча алда баруын әйтте. Монда сүз төзелеш, сәнәгать җитештерүе, инвестицияләр һәм башка юнәлешләр турында бара. Узган ел нәтиҗәләре буенча төбәкнең тулай төбәк продукты (ВРП) 3,3 трлн сумга җиткән. «Сезнең тырышлыгыгыз белән менә шундый уңышлы республикада яшибез!» – диде ул.

Беренче бүләкләр – «Ватан алдындагы казанышлар өчен» I дәрәҗә ордены медале «Зенит» волейбол клубы спортчылары Артем Вольвич, Валентин Голубев, Максим Михайловка тапшырылды. Иң яхшы химик, табиб, юрист, төзүче, архитектор, машина төзүчеләр… Дәүләт бүләкләрен алучылар арасында кемнәр генә юк!

Алабуга районы «Яңа Юраш» агрофирмасының машина белән саву операторы Вәсилә Исхаковага «Татарстанның атказанган терлекчесе» исеме бирелде. Көнгә 100 сыер сава ул. Мәктәпне тәмамлагач, Вәсилә авылда калган. 18 яшьтән бирле, 37 ел – фермада. Вәсилә ханымның шатлыгын күзләрендәге очкыннардан ук чамалап була. Кремльгә чакыру турында ишеткәч, сөенечтән хәтта елап та алган. «Эшләсәң, хезмәтне бәяли беләләр. Бу – минем өчен иң зур бүләк», – ди.

– Әнием гомер буе сыер сауды, апам да, мин дә аның юлыннан киттек. Авылда калуыма сөенәм. Бөтен кеше дә шәһәргә китә һәм ак яка гына булып бетә алмый. Колхозга минем кебек сыер савучылар да кирәк. Эшемнән канәгать, директор акчаны вакытында түләп бара, риза булып эшлим. Элек кул белән сава идек, хәзер хезмәтебез күпкә җиңел. Иртән сәгать өч тулып киткәч үк торам. Ун көн эшләп, бер көн ял итәбез. Бер дә зарланырлык түгел, – ди 54 яшьлек Вәсилә Исхакова.

Эше турында шулкадәр тәмләп сөйли, әйтерсең фермага кунакка йөри. Сәламәтлеге турында да сорашмыйча кала алмадык. Анысында да, зарланмыйча гына, сызлый инде, дип кулларына ымлады. Чын сабыр татар хатыны!

Балтач районының «Труд» колхозы тракторчысы Олег Ураков исә бүгеннән «Татарстанның атказанган механизаторы» исемен йөртә. 5–6 яшьлек чагында ук тракторчы әтисе янында кайнаша торган булган. 7 сыйныфтан техниканы үзе йөртә башлаган. Армиядән кайтуга, тракторга утырган… 35 ел күз ачып йомганчы узып та киткән.

– Беренче тракторым – ДТ-75. Элек салкын була иде, хәзер җылы гаражда эшлибез. Язгы кыр эшләрендә катнашам. Көз көне фермада терлекләргә сенаж салам. Мондый дәрәҗәле исем алырмын дип башыма да китермәдем. Зурлагач, рәхмәт. Бу эштән башканы күз алдына да китермим. Китәм дип йөргән чагымда, «эшеңне ташлама!» дип кисәткән төш керде. Менә бит хәзер әҗерен күрәм, – ди 55 яшьлек Олег Ураков.

Бүләкләнүчеләр арасында таныш йөзләр дә күренә. Галим Энгель Таһиров, диктор Эльмира Хамматова, Татарстан Язучылар берлеге рәисе урынбасары шагыйрь Рифат Корбанов, җырчы Нурзадә…

– Бик дулкынланам. Бу хакта, бүләгемне алганда, Фәрит Хәйрулловичка да әйттем. Ул миңа: «Син беркайчан да картаймыйсың, үзгәрмисең», – диде. Иҗат шулай яшәтә, дим. Телевидениедә иҗатымның беренче баскычлары башланып китте. Миннән шәхес ясаган өчен рәхмәт. Казан дәүләт мәдәният институтында бик сөенеп эшлим. Анда заманча тормыш кайный. Төрле проектлар, конкурслар уздырабыз. Яшьләрне матур итеп сөйләргә, дөрес сулыш алырга өйрәтәбез. Бүген татар эстрадасында, театрларда эшләүче укучыларым белән горурланам, – ди Казан дәүләт мәдәният институты профессоры Эльмира Хамматова.

Җырчы Нурзадә Вәлиуллина өчен дә сөенечле көн. «Гөлзадә» иҗат студиясе» оешмасы солисты-вокалистына «Татарстанның атказанган артисты» исеме бирелде.

– Көтелгән иде инде. Хезмәтемне бәяләгән өчен рәхмәт. Миңа караганда да ныграк көткән, кызганыч, шушы көннәрне күрмәгән әниемнең өлеше зур монда. Бу бүләк аңа багышлана, – диде Нурзадә.

Тантанадан барысы да орден-медальләр тагып кайтып китте. Горурлык хисе дә арткандыр. Тагын бер төн йокысыз булыр, ахры.

Сәрия МИФТАХОВА

Берсе булмаса, икенчесе бар

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Надия Шемякина сүзләренә караганда, дәүләт даруханәләрендә бәяләр җитди контрольдә тотыла. Росздравнадзор, Монополиягә каршы федераль хезмәт идарәсе аларга даими күзәтчелек итә. «Соңгы арада бездә яшәү өчен мөһим булган дарулар 0,9 процентка артты. Калган төр дарулар дәүләт тарафыннан түгел, базар тарафыннан көйләнә. Шуңа күрә, гомумән алганда, дарулар уртача 5 процентка кыйммәтләнде», – ди белгеч.

Дару кайтаруда да тоткарлыклар булмас дип тынычландыралар. Ник дигәндә, җитештерүчеләр дарулар график буенча кайтарылачак дип ышандырган. Санкцияләр аркасында дарулар җитештерә торган бер генә чит ил оешмасы да Россия базарыннан китмәгән.

«Таттехмедфарм» идарәсе мәгълүматларына караганда, бүген республика 97 процентка дарулар белән тәэмин ителгән. Быел Татарстанга дәүләт контракты буенча 6,3 миллиард сумлык дару кайтачак. Шуларның 5,5 миллиард сумы – даруларга, 18,8 миллион сумы халыкны бушлай дарулар белән тәэмин итүгә юнәлдерелгән. Хәзерге вакытта республикага 3,7 миллиард сумлык дару кайткан инде. Аларның бер өлеше республика даруханәләренә, дәвалау оешмаларына таратылган. Бу дарулар тагын 2,5–3 айга җитәр дип планлаштыралар. Халыкны бушлай тәэмин итү өчен каралган дарулар исә 4,5–5 айга җитәчәк дип фаразлана. Хәзерге вакытта «Таттехмедфарм» складларында тагын 2,2 миллиард сумлык дару запасы бар. 10 майга кадәр республикага өченче кварталга исәпләнгән дарулар кайтачак.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

Яшәеш

Чүпкә батмабызмы?

Мамадышта полигон юк, Әгерҗедә булганы да ябыла. Калдыкларга күмелеп калмас өчен, тиз арада махсус станцияләр төзү кирәк. Татарстанның Тарифлар буенча дәүләт комитетында узган очрашуда әнә шулай диделәр.

«Халык контроле» порталына да чүпкә бәйле сораулар күп килә икән. Порталның кулланучылар белән элемтә бүлеге җитәкчесе Рөстәм Низамиев узган ел көнкүреш калдыкларын чыгаруга кагылышлы 807, контейнер мәйданнарына бәйле 1200 мөрәҗәгать килгәнен әйтте.

– Узган ел республикада 200дән артык контейнер мәйданчыгы яңартылды һәм төзелде. Әмма ул безгә җитми. Хәзерге вакытта Татарстанда 7 меңнән артык контейнер мәйданы кирәк, – диде ул.

Татарстанның Тарифлар буенча дәүләт комитеты рәисе Александр Груничев чүпкә бәйле сорауларны урында ук хәл итәргә кирәклеген әйтте.

– Без чүп проблемасын ничек тиз генә чишеп булу юлларын уйлыйбыз. Тиздән уртак фикергә килеп, бу хакта җиткерербез, – диде ул.

Очрашуда калдыкларны чыгару буенча төбәк операторлары да катнашты. «ГРИНТА» оешмасының генераль директоры Светлана Ярлыченко калдыклар белән эш итү буенча махсус комплекс төзергә кирәклеген әйтте.

– Бу комплекс чүп-чарны сортларга аеру заводын, калдыкларны компостлау мәйданчыгын һәм каты көнкүреш калдыклары полигонын үз эченә алачак. Республикадагы эшләүче полигоннарның куллану вакыты бетеп килә. Аларга инде башка чүп ташлап булмый. Шуңа да безгә, калдыкларны махсус техникадан бушату өчен, кимендә 11 станция төзергә кирәк, – диде ул.

Инде төзелеш эшләре дә планлаштырылган. Әгерҗе, Нурлат, Актанышта мондый станцияләр төзергә җыеналар. Мамадышта инде ул төзелеп ята икән. Моның өчен 59 миллион сум акча тотылачак. Мамадыштагысы 1 июньгә кулланута тапшырылачак дип ышандыралар. Әгерҗенеке 1 сентябрьдә, Актаныш һәм Нурлатта ноябрь аенда сафка басар дип көтелә.

«ПЖКХ» оешмасы директоры Сергей Богатов Казанда икенчел чималны җыя башлаячакбыз, диде. Аларның да проблемалары шактый.

– Без хәзерге вакытта чүп чыгаруны күзәтеп торабыз. Бу безгә калдыкларны вакытында чыгаруны контрольдә тотарга мөмкинлек бирә, – диде ул. Эшлисе эшләргә дә тукталды.

– «Восточный» полигонының икенче өлешен төзеп бетерергә кирәк. Шулай ук чүп-чарны сортларга аеру комплексын, төяү мәйданчыкларын инвестиция программасы буенча төзибез, – диде ул. – Чүп өчен түләргә теләмәүчеләр шактый. Казанда шәхси йортлар белән яшәүчеләргә кирәкле санда контейнерлар юк. Машиналар саны арту да безнең эшчәнлеккә комачау итә. Безнең хезмәткәрләр күп вакыт ишегалларындагы чүпләрне алып китә алмый.

Болары – хәл итә алырлык проблемалар. Очрашуда чүптән котылуның яңа юлларын да эзләүләрен әйттеләр. Шулай ук тәкъдим ителгәннәре дә яклау тапты. Шунысы сөенечле: чүп чыгаручы төбәк операторларына санкцияләр мәшәкать тудырмаган. Техника да, аларга запас кирәк-ярак та җитәрлек икән.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

«Татар-информ»

АПРЕЛЬ АЕНДА БУЛАЧАК ҮЗГӘРЕШЛӘР

Социаль пенсияләр 8,6 процентка арта, балалар кэшбегы, кешеләр һәм бизнес өчен салым ташламалары пәйда була. Россия законнарына кертеләчәк үзгәрешләрнең иң мөһимнәрен туплап, укучыларыбыз игътибарына тәкъдим итәбез.

ПЕНСИЯ АРТА

Бу айда социаль пенсияләр 8,6 процентка арта. Әмма халыкка ярдәм итүнең бердәнбер чарасы түгел әле бу. Россия Президенты басым ясап әйткәнчә, озакламый, пособие һәм пенсияләрне кертеп, барлык социаль түләүләр күләме үсәчәк.

БАЛАЛАРГА – ЯҢА ТҮЛӘҮ

1 апрельдән балалы гаиләләргә яңа түләү гамәлгә кертелә. Хәзер ярдәм 8дән 16 яшькә кадәр бала үстерүче ялгыз ана яки ялгыз атага гына түгел, бәлки тулы гаиләләргә дә күрсәтеләчәк. Әлеге пособие гаиләнең мохтаҗлыгына – гаиләдәге уртача керем күләменә карап түләнә. Түләү төбәктә билгеләнгән яшәү минимумы күләменең 50, 75 яки 100 проценты кадәр булырга мөмкин.

Яңа пособие 1 майдан түләнә башлый. Аны берьюлы ике ай – апрель һәм май өчен бирәчәкләр.

ҖӘЙГЕ ЛАГЕРЬ БӘЯСЕ ЯРТЫЛАШ КИМИ

Быел балалар кэшбегы 31 мартта гамәлгә керде. Димәк, апрель аенда балаларга җәйге лагерьга юллама алып, аның яртысын кире кайтарырга мөмкин. Әйтик, юллама 40 мең сум торса, картага 20 меңе кире кайта дигән сүз. Юллама хакы кыйммәтрәккә төшсә дә, шул сумма кайтарыла, чөнки ул – кэшбекның чик күрсәткече. Кэшбек программасы дәүләтнекеләргә дә, шулай ук шәхси лагерьларга да кагыла.

Сүз уңаеннан, быел программага узган елдагыдан (5 миллиард сум) күбрәк – 7,5 миллиард сум акча бирелүен әйтеп үтик.

ҮСМЕРЛӘР ӨЧЕН ПОРТАЛ

Апрельдән башлап, «Дәүләт хезмәтләре» порталында өлкәннәр генә түгел, балигъ булмаганнар да теркәлә алачак.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Паспорт алган үсмерләр мөстәкыйль рәвештә үзләре теркәләчәк, ә 14 яше тулмаганнарны әти-әниләре теркәячәк. Балигъ булмаган баланың һәм әти-әнисенең учет язуы бер-берсенә бәйле булачак.

14 яшьтәге һәм аннан зуррак үсмерләргә порталда теркәлү өчен заявка тутырырга кирәк. Анда паспорт сериясе һәм номеры, адрес, СНИЛС, телефон номеры һәм электрон почта адресы күрсәтелергә тиеш. Балага 14 яшь тулмаган очракта, ата-ананың учет язуында баланың туу турында таныклыгы реквизитлары, теркәлү адресы, телефон номеры, электрон почта адресы һәм СНИЛС язып куела. Шулай ук 1 апрельдән социаль ярдәм чарасын рәсмиләштерү җиңеләя.

ЧИТ ИЛ ДАРУЛАРЫ ТИЗРӘК КИЛЕП ҖИТӘЧӘК

26 марттан чит ил даруларын Россия базарына кертүне гадиләштерердәй закон эшли башлады. Аның нигезендә, дару капларын, андагы язуларны безнең илгә яраклы итеп үзгәртү вакытлыча юкка чыгарыла: даруларны чит ил капларында сатарга мөмкин булачак. Шулай ук күптән түгел генә теркәлгән препаратларны әйләнешкә кертү өчен, Росздравнадзорның рөхсәт бирүе мәҗбүри итеп куелмаячак.

Моннан тыш законда 10 апрельдән федераль башкарма хакимият органнарына Донецк һәм Луганск республикаларыннан мәҗбүри күченүчеләргә Россия территориясендә беренчел медицина ярдәме күрсәтү тәртибен раслау хокукы билгеләнгән.

ТИЗ ТҮЛӘҮ ГАДИЛӘШТЕРЕЛӘ

1 апрельдән тиз түләүләр системасы (СБП) ярдәмендә түләү гадиләштерелә. Анда катнашучы банклар кешеләрдән юридик затларга һәм хосусый эшмәкәрләргә мобиль кушымта аша акча җибәрү мөмкинлеген булдырырга тиеш.

ХӘРБИ ХӘРӘКӘТЛӘР ВЕТЕРАНЫ СТАТУСЫ БИРЕЛӘ

Украинада, шулай ук Донецк һәм Луганск республикаларында махсус хәрби операциядә катнашучыларга хәрби хәрәкәтләр ветераны һәм хәрби хәрәкәтләр инвалиды статусы билгеләнәчәк. Бу аларга салым, транспорт, җир, торак буенча социаль ярдәм чараларына, шулай ук коммуналь түләүләр буенча ташламаларга хокук бирә.

САЛЫМ ТҮЛӘҮГӘ ТАШЛАМАЛАР КЕРТЕЛӘ

26 марттан халыкны һәм бизнесны яклау чаралары гамәлгә керде. Алар нигезендә, 2021–2022 елларда банктагы саклаудагы акчага өстәлгән проценттан салым түләү юкка чыгарылды. Шул ук вакытта милеккә һәм җиргә салым күләмен исәпләү өчен кадастр бәясе 2022 елның 1 гыйнварында ничек булса, шулай сакланып кала. Ә IT-компанияләр өч ел дәвамында табышка салым түләми.

ДӘҮЛӘТ ОРГАННАРЫ ТУРЫНДА ЯЛГАН ХӘБӘР ӨЧЕН – ШТРАФ

5 апрельдән Россия дәүләт органнарының чит илләрдәге эше турында фейк тараткан өчен җаваплылыкны күздә тоткан закон үз көченә керә. Биредә Россия илчелекләре һәм консуллыклары, прокуратура, Росгвардия, МЧС һәм Тикшерү комитеты турында сүз бара. Законны бозучыларга Россия Кораллы Көчләренең гамәлләре турында ялган хәбәр таратучыларга нинди җәза чаралары күздә тотылса, шундый ук чаралар күреләчәк (штраф яки өч елга кадәр иректән мәхрүм итү).

Г.Тукай исемендәге дәүләт премиясенә кандидатлар

ТЫНГЫСЫЗ ҖАН

Урау юллар аша музыка сәнгатенә килеп кергән Риф Гатауллинны тынгысыз җан дип атау юкка түгел. Юкса бит үз иҗатын гына кайгырта ала иде. Ә ул һәвәскәрләр иҗатын да туплый, фәнни-тарихи юнәлештә дә эшчәнлек алып бара.

Риф Гатауллин 1950 елның 25 февралендә Югары Ослан районының табигатьнең искиткеч матур урынына урнашкан кечкенә генә Яңа Болгар авылында туып үсә. Моңга, җырга, музыкага сәләтне Ходай аңа тумыштан ук күпләп бирә. Әйтик, җиде яшендә үзлегеннән тальян гармунда уйнарга өйрәнеп, бөтен авылдашларының күңелен күрә. Музыка аның тормыш рәвешенә әверелеп, инде 7 нче сыйныфта укыганда баянда уйный башлый.

Авылның мәдәни чаралары аның катнашыннан башка узмый. Ул гынамы, үзе көйләр яза һәм үзе үк башкара да. Авылдашлары бернинди шиксез аны җырчы, музыкант булыр дип юрый. Ләкин 10 нчы сыйныфны тәмамлагач, Риф, барысын гаҗәпләндереп, музыка мәктәбенә түгел, ә Казан химия-технология институтына укырга керә. Күңелендәге музыка сәләте, байлыгы аңа һич кенә дә тынгылык бирми, күрәсең, ул институттагы хор түгәрәгенә йөреп җырлый башлый. Ә инде данлыклы композитор Сара Садыйкова белән танышкач, аннан практик дәресләр дә ала башлагач, Рифнең музыка, җыр тормышы икеләтә җанланып китә. Сара Садыйкова аның үтә дә моңга бай тавышын югары бәяли һәм Рифкә зур хорның солисты вазыйфасын йөкли.

Сара Садыйкова, аеруча музыка җанлы егет икәнлеген аңлап, аңа химия-технология институтын ташлап, музыка училищесына укырга керергә киңәш итә. Әлбәттә, Риф бу киңәш белән килешә һәм аның тулысы белән музыкага багышланган яңа тормышы башлана. Җыр белән бергә көйләр язу осталыгы да ачыла. Шунда ул Әхмәт Ерикәйнең «Әй, күңелле җәйге кичләр» дигән шигыренә беренче җырын яза.

Сара Садыйкова белән аралашу еллары Рифкә сәнгать дөньясының бөтен нечкәлекләрен өйрәнергә ярдәм итә, карашын киңәйтә. Танылган шәхесләр, каләм осталары белән танышу аның музыка өлкәсендәге эшчәнлеген тагы да ныграк үстерә. Бигрәк тә ул еллардагы Фәннур Сафин белән булган иҗади дуслыгы бик күп яңа көйләр язарга этәрә. Мәсәлән, «Бир кулыңны», «Хушлашырга ашыкма», «Ялгыз көймә» һәм башка бик күп әсәрләре халкыбызның иң популяр, иң яратып башкарыла торган җырларына әверелделәр һәм хәзер дә яңгырыйлар.

Музыка училищесын тәмамлаганнан соң Риф 1974 елда Казан консерваториясенең вокал бүлегенә укырга керә. Студент елларында да ул көйләр иҗат итүен дәвам итә. Шул елларда язылган «Серле йөрәк» (М.Әгъләмов сүз.), «Гармун алыйк әле, дускай» (Г.Шакиров сүз.) җырлары яшь композиторның популярлыгын тагын да арттыра. Ни гаҗәп, дипломлы вокал җырчысы булу да Рифне тынычландырмый. Аның йөрәгендә югары белемле профессиональ композитор булу теләге туа. Шушы теләкләрен, уйларын ул вакыттагы консерватория ректоры Нәҗип Җиһановка аңлатып бирә. Тыңлагач, Нәҗип Җиһанов икенче югары музыка дипломының кирәк түгеллеген аңлатырга тырыша, ләкин Риф Гатауллинның максатчанлыгы, үҗәтлеге барысыннан да көчлерәк булып чыга һәм ул 1994 елда югары белемле композитор дипломын алуга ирешә.

Рифнең үзенчәлекле, халыкчан иҗат җимешләре тыңлаучылары һәм музыка белгечләре тарафыннан бик тиз югары бәяләнә. 1988 елда балалар өчен язган көйләре өчен ул Муса Җәлил исемендәге бүләккә лаек була.

Акрынлап, киң музыка белемле һәм карашлы композитор Риф Гатауллинның яңа төр, катлаулырак әсәрләре дөнья күрә.

Татар халкы тудырган «Сак-Сок» бәетенә нигезләнеп язылган симфониясе Риф Гатауллинны композитор һәм музыкант буларак та аның талантын берничә баскычка югары күтәрә. Симфония кебек катлаулы музыка әсәренә алыну ул җиңел генә туа торган лирик җыр язу түгел. Аның өчен бик тирән музыка белемле, халык иҗатын бөтен төсмерләре, тарихи нечкәлеге белән аңлый белә торган шәхес булырга кирәк.

Бу музыкаль әсәр Риф Гатауллинны, композитор буларак, безнең олпат классик композиторларыбыз белән бер дәрәҗәгә куя. Аның бу зур хезмәтен музыка белгечләре дә, тамашачылар да югары бәяләделәр.

Риф Гатауллин музыка дөньясында гел үз мәнфәгатьләре өчен генә яшәми. Аны, соңгы вакыттагы татар халык иҗаты, татар музыкасының соңгы еллардагы хәле, чит-ят музыкаль агымнарның безнең татар музыка дөньясына үтеп кереп милли рухын юа башлау проблемалары борчый. Бигрәк тә яшь үзешчән композиторларның үзебезнең халык җырларына ихтирамнарын киметеп, аларны санга сукмаулары көендерә.

Инде сиксәненче еллар азагында ук, ул СССР җирлегендә яшәүче татар музыкантларын, көй язучыларын бергә җыйнап, күрештереп, аларның иҗатларын тыңлап, тикшереп карап, бер үк вакытта аларга көй язу буенча методик ярдәм күрсәтү теләге туа. 1988 елның март башында башкалабыз Казанда барлык үзешчән композиторларның беренче очрашу фестивале уздырыла һәм шушы тарихи, бик мөһим мәдәни чараны әзерләү, уздыруда Риф Гатауллинның оештыра белү һәм кешеләрне үз артыннан ияртү сәләте ачыла. Ул 1990 елдан Татарстан Республикасының халык иҗаты һәм мәдәни-агарту эшләре фәнни-методик үзәгенең баш белгече булып билгеләнә һәм җиң сызганып бар булганлыгын борынгы һәм хәзерге заман халык иҗатын өйрәнүгә, торгызуга һәм оештыруга багышлый.

Соңгы елларда ул бик зур, бәяләп бетергесез, үтә дә кирәкле фәнни-тарихи хезмәт әзерли. Архив һәм матбугат материалларында актарынып, татар җырын, мәдәниятен үстерүгә өлеш керткән БДБ илләрендә яшәүче 200дән артык композиторның тормышына, иҗатына багышланган дәлилле язмаларны туплап, татар үзешчән композиторларының антологиясен әзерләде һәм нәшриятка тапшыру нияте белән яши. Бу – аның татар музыкасы тарихына, мәдәниятенә багышланган бәяләп бетермәслек кыйммәтле хезмәте, үзешчән композиторларның хезмәтләрен, исемнәрен мәңгеләштерүгә куйган изге гамәле.

Аерым җылы сүзләрне аналарга багышлап эшләнгән «Әниләр турында 100 җыр» исемендәге җырлар җыентыгы турында әйтәсе килә. Бу җыентыкка әниләргә багышланган, төрле җыр бәйгеләрендә, фестивальләрендә җиңеп, лауреат һәм дипломат исеменә лаек булып киң таралган җырлар тупланган.

Композитор Риф Гатауллинның иҗаты киң кырлы. Ул 200дән артык төрле жанрдагы җырлар һәм романслар иҗат иткән. Халкыбызның бөек язучылары Габдулла Тукай, Муса Җәлил, Хәсән Туфан, Әхмәт Ерикәй, Илдар Юзеев, Равил Фәйзуллин, Фәнис Яруллин, Гөлшат Зәйнашева шигырьләренә ул чын халыкчан, күңелгә ятышлы җырлар язды.

Үзенең иҗат гомерендә ул бик күп аңа гына хас үзенчәлекле, эчтәлекле, тиз отылып истә калырлык, хәтердә сакланырлык симфоник, халык музыка коралларында башкарыла торган, хорлар өчен һәм лирик әсәрләр тудырды. Аның һәр иҗат җимеше үзенең халыкчанлыгы, миллилеге белән тыңлаучыларны үзенә җәлеп итеп тора.



Риф Гатауллин һәрвакыт хәрәкәттә, эзләнүдә, халык, тамашачы арасында. Ул – татар халык иҗаты җырларын барлык мөмкинлекләрне кулланып пропагандалаучы да. Халкыбызның күренекле сәнгать, мәдәният, музыка әһелләренә багышланган теле-радио аша чыгышлары барысы да киң җәмәгатьчелеккә, тыңлаучыларга милләтебезнең шушындый күренекле улларының тормышы һәм иҗаты турында гади татар телендә аңлатып бирү. «Җыр чишмәләре» исемендә халкыбызның яраткан композиторлары Фәтхрахман Әхмәдиев, Шакир Мәҗитов, Әкрәм Даутов, Арслан Батыршин, Ифрат Хисамов турындагы әңгәмә-чыгышлары – әнә шуларның бер якты чагылышы.

Риф Гатауллинның кешелеклелеге турында искәртмәсәм, язмам тулы булмас. Шундый киң кырлы белемле, бар татар дөньясына танылган, күренекле кеше булса да, Риф һәрвакыт һәм һәр кеше өчен ачык күңелле, якты йөзле, гади, тәмле, үтемле телле кеше булып кала белә. Сер түгел, кайбер үзен «йолдыз»га тиңләүчеләр сәлам дә бирә белмиләр. Рифнең эчке югары культурасы, кешегә кеше итеп карый белүе, үзен дә гади җан иясе итеп исәпли белүе һәркемдә аңа карата зур хөрмәт һәм ихтирам тудыра. Шуңа күрә дә без – композиторлар, мәдәният вәкилләре – аңа зур хөрмәт белән карыйбыз, олылыйбыз, аңа ышанабыз. Шушы кадәр гигант хезмәтен, бар гомерен халкыбызга, милләтебезгә, мәдәниятебезгә тулысы белән үзен багышлавын истә тотып, Риф Хөббул улы Гатауллин татар халкының иң югары бүләге – Габдулла Тукай премиясенә лаек дип исәплим.

Рубис ЗАРИПОВ

Моңсаралы Тутай

2022 елның 10 июнендә Апас районының Тутай авылында Сара Садыйкова музее ачылуга – 30 ел, ә Моңсараның дөньяга килүенә 116 ел тула. Тарихка күз салсак, музей башта тутайлылар башлангычы белән мәдәният йортының кысан гына бүлмәсендә ишеген ачты. Ул чакта әлеге вакыйга дөньяны шаулатырлык яңалыкка әйләнде. Сара Садыйкованың әнисе ягыннан бабасы Әхмәдиша туган һәм үскән җир, шулай итеп, мәңгеләштерелде.

Бер үк вакытта тутайлылар «татар сандугачы»ның – Сара Садыйкованың да исемен хәтергә теркәде. Монда беренчеләрдән булып трибун шагыйрь Мәхмүт Хөсәен кунакка килде, кич кунып китте һәм искитәрлек «Моң музее» шигырен язды. Анда мондый юллар бар: «Без Саралы булу белән бөек – Тукай җаны кебек. Без Саралы булу белән көчле – Сәйдәш маршы төсле». Шигырь «Рәхмәт сезгә, олы җанлы тутайлылар!..» – дип бетә.

Шул заманнан бирле ноябрь аенда бирегә Сара Садыйкованың туган көненә Казаннан артистлар кайта башлады. Әлеге матур гадәт күп еллар кабатланды. Шагыйрьләр, җырчылар, музыкантлар кунакчыл җирлектә рәхәтләнеп ял итте. Сәнгать авыл кешеләренең рухи дөньясын баетты һәм нығытты.

2006 елның 15 декабрендә, композитор җырчының 100 еллыгына, ниһаять, гүзәл заманча әкияти корылма – Сара Садыйкованың иркен музее калыкты. Ул үзенең күркәмлеге белән ерактан ук җәлеп итә, ерак чакрымнардан сәлам биреп тора. Җирле җитәкче Ринат Гыйсмәтуллин башлап җибәргән төзелеш, район хакимияте башлыгы этәргеч биргәч, менә шулай рух балкышына әйләнде. Кадер-данлау кичәсен югары дәрәҗәдә үткәргәннәре өчен аларга бик зур рәхмәт. Яңа музейның ачылышы онытылмаслык бәйрәм булды. Тантанада район җәмәгатьчелеге, күп казан кунаклары катнашты. Аның тәэсире күңелдә бүгенгә кадәр сакланып калды. Шуның җылысы белән тернәкләнү чорында – 2007–2009 елларда миңа Казаннан авылга кайтып, музейга җитәкчелек итәргә дә насыйп булды. Иң әүвәл, мирасханә әйберләренең исемлеген төзегәч, кече сәхнә җиһазланды, монда Казаннан кайтартылган пианино урнаштырылды. Уен коралы үз тирәсенә артистларны, шагыйрьләрне, музыкантларны, сәхнә ветераннарын туплады, ике заллы музейда иҗат кичәләре, концертлар, бәйрәм чаралары үткәрергә юл ачты.

Музей чын-чынлап матур өй кебек уңайлы. Китапханәсе бик бай. Төп һәм фәнни-ярдәмчел фондта меңнән артык экспонат исәпләнә. Аларның күбесе – композиторның шәхси әйберләре. Монда Сара Садыйкова ялгыз да түгел. Ул аралашкан җырчыларның, драматургларның, язучы-шагыйрьләрнең, режиссер-композиторларның фотолары күп. Республика, чит ил рәссамнарының рәсемнәре дә үз урынында тора.

Әмма Тутайда мәдәният йортының, Сара Садыйкова исемендәге мәктәпнең ябылуы нык үкенечле. Мондый чигенеш ясалган заманда бүген музей рухи байлык булып кына калмыйча, рухи-әхлакый тәрбияне дәвам иттерә, композиторның иҗади мирасын, халыкның мәдәни традицияләрен күңелдә яшәтә. Шуңа күрә музей район һәм республика җитәкчеләренең игътибар үзәгендә булырга тиеш. Исеме татар дөньясына мәгълүм булган, җырлары милләттәшләр күңелен җылыткан Сара Садыйкова музеена сәяхәтчеләр килеп торсын. Автобус Тутайны читләтеп үтмәсен!

Әлфия Газиз кызы АЙДАРСКАЯ

БОРЫНГЫ МИРАСЫБЫЗ САГЫНДА

1980 ел ахырларында республикабызда «Көмеш дага» исемле туристик маршрут ачу кирәклеге турында сүз башладылар. Бу маршрут Болгардан башланып, Суар һәм Биләр калалары аша Җүкәтауга кадәр сузылырга тиеш иде. Кама аръягы – Идел Болгарының халык иң тыгыз урнашкан үзәк җирләре. Таш гасырдан башлап тимер гасырга кадәрге чорларда яшәгән борынгы кабиләләрнең археологик истәлекләре бихисап биредә. Табигате матур бу якларның. Уйлап эш иткәндә, тикшеренү, төзү эшләренә акчаны кызганмаганда, менә дигән туристик маршрут булачак ул!

Кызыклы проектны тормышка ашыруда беренче чиратта, әлбәттә, археологлардан зур ярдәм сорала иде. Озак уйлап тормадык, 1990 елның май башында без, Фаяз Хуҗин җитәкчелегендәге бер төркем археологлар, гыйльми сәяхәткә чыгып киттек. Бер ай вакыт эчендә, Суар, Биләр калаларын үтеп, Спас, Әлки, Алексеевск, Аксубай, Чистай районнарында урнашкан йөздән артык археология истәлеген тикшереп, ниһаять, исеме рус елъязмаларында теркәлеп калган бер Болгар бәклегенең башкаласы Җүкәтауга килеп җиттек.

Бик матур урында урнашкан икән – Кама елгасының сул ягында, биек тау башында. Монда элек Җүкәтауның каласы, ягъни өч рәт балчык үрләр, чокырлар, агач стеналар белән яхшылап ныгытылган өлеше булган. Кызганыч, мәйданы 6–7 гектардан артмаган каланың яртысыннан артыгын инде Чистай элеваторы җимереп бетергән.

Тау башыннан карап торабыз: шәһәрнең төп халкы яши торган өлеше – һөнәрчеләр һәм сәүдәгәрләр бистәсе Калатауга каршы яктагы җирләрне биләп торган икән. Ул якка Каманың сулъяк кушылдыгы Киле елгасы аша чыгарга кирәк. Бу җирләр сөрелгән, шәһәр халкы бәрәңге утырта, бер яктарак зур гына җиләк-җимеш бакчасы бар. Такта яру кече предприятиесе (пилорама) урнашкан. Шул тирәләргә юнәләбез. Сөрелгән җир өстендә – чүлмәк китекләре, хайван сөякләре. Алтын Урда чорына караган акчалар да табып алдык.

Сәяхәтебезне тәмамлап, Казанга юл тоттык. Бер айлык сәяхәт күңелләрдә матур хатирәләр калдырды. Фаяз дус кына тынычлыгын югалтты. Соңыннан сәбәбен әйтте – Җүкәтау археологик яктан бик начар өйрәнелгән, анда казу эшләре башлап җибәрергә ниятли икән. Фаяз Хуҗин Идел Болгарстаны башкаласы – «Бөек шәһәр» Биләрне тикшерү экспедициясен дә җитәкли. Ташлап китәсе килми. Икесен бергә күтәрә алырмын микән, дип борчыла.

Бер елдан соң ул яңадан Җүкәтауга чыгып китә. Үзе әйтмешли, болай гына, болгар хәрабәләрен сагынып. Калатауга килсә, күзләренә ышанмыйча катып кала: аның әле моңарчы җимерелүләрдән сакланып калган зур гына бер өлешен агач койма белән уратып алганнар. Дистәләгән багана чокырлары борынгы катламны җимергән. «Әллә җимеш бакчасы була микән?» – дип уйлый башта Фаяз. Авыл советына йөгереп барып, тиз генә белешә: болгар каласы булган урында урыс зираты ясамакчылар икән! Башка җирдә урын таба алмаганнар, имеш. Болгар истәлегенең тарихи әһәмиятен аңлатып карый – тыңларга да теләмиләр. Чаба шундук Чистай районы хакимиятенә, шалтырата Казанга, Мәдәният министрлыгына. Ул чактагы район башлыгы Абрек Хәйруллин егетнең хәленә керә, машинасына утыртып, икәүләп Җүкәтауга юнәләләр. Нәтиҗәсе шул: ике-өч көн эчендә коймаларны сүтеп тә аталар. Бу кыргый гамәлдән шулай, чагыштырмача җиңел котылалар.

Әмма көн кебек ачык: системалы рәвештә археологик казу эшләре алып барылмаса, ягъни бу истәлекнең тарихыбыз өчен чын әһәмиятен фактик материаллар белән аңлатып күрсәтелмәсә, Җүкәтауның язмышы һәрдаим кыл өстендә торачак. Борчыган уйлары-планнары белән Фаяз Хуҗин Болгар дәүләт тарих-архитектура музей-тыюлыгы директоры Җәмил Мөхәммәтшинга килә. Тарих институты планнарында Җүкәтауда казулар каралмагач, экспедицияне финанслау мәсьәләсен хәл итү мөмкин түгел иде. «Җәмил әфәнде булышты, табылдыкларны музей-тыюлык фондларына тапшыру шарты белән экспедиция өчен бераз акча да табып бирде», – дип искә ала Фаяз. Шулай итеп, 1991 елның июнь башында Җүкәтау яңадан археологлар кулына эләкте.

Археологиядә шулай кабул ителгән инде: ничек кенә яхшы тикшерелгән объект булмасын, эшне разведкалардан башлыйбыз. Кыска гына вакыт эчендә без борынгы каланың ким дигәндә 140–150 гектар мәйданда урнашкан булуын исбатлый алдык. Җүкәтауның иң борынгы катламнары сакланган булырга тиешле бер урында казу эшләрен башлап җибәрдек. Алтын Урда катламын казыганда, коллекциябез әллә никадәр кыйммәтле савыт-саба ватыклары, дистәдән артык көмеш һәм бакыр акча, үлчәү тәлинкәсе һәм герләр, бизәнү әйберләре белән тулыланды.

Фаяз Шәрип улы Хуҗинны 1994 елда Казан Кремлендә башланып киткән киң күләмле казу эшләренең җитәкчесе итеп билгеләделәр. Җүкәтауны ул үзенең шәкерте

Наил Нәбиуллинга калдырып китте. Булган егет – кызыксынып эшләде, калатауның саклану ныгытмаларын, һөнәрчелек бистәләрен, мөселман зиратларын да тикшерде, бик күп яңа материал туплады. Алай гына да түгел, остазы тәкъдиме белән археологик күзәтүләрне ул Чистай шәһәренең үзендә башлап җибәрде.

Фаяз дусның кулы җиңел булды – аның тырышлыгы белән юкка чыгудан котылып калган Җүкәтауны һәм аның тирә-юнендә урнашкан болгар чоры истәлекләрен өйрәнү бүген дә уңышлы гына дәвам итә. Табылдыклары Чистай һәм Казан музейларында урын алды. Җүкәтау турында документаль фильмнар төшерелде, туристлар да аны читләтеп үтми башладылар.

Бу – ныклап истә калган бер мисал гына. Борынгы рухи, матди мирасыбызны саклау, өйрәнү, аны халыкка, дөньяга җиткерү күп юнәлештә бара. Фаязны Казанның 1000 еллык юбилеен исбатлауны җитәкләгән, бу үзәк мирасыбызны пропагандалаган, «казанлыларга рухи бәйрәм бүләк иткән шәхес» дип атыйлар. Әмма җитди фәнни китаплар халыкка барып җитми. Бик четерекле бу эшне дә Фаяз үз җилкәсенә алды: татар, рус телләрендә мавыктыргыч, халыкка аңлаешлы күп китаплар чыгарды. Мирасыбызны Татарстанга килгән югары делегацияләргә күрсәткәндә, чит ил туристларына җиткергәндә дә аны эзләп табалар. Ул укытучылар, укучылар, студентлар арасында кайный. Мирасыбызны халыкка җиткерү эшендә аның телевизор экраннарыннан төшкәне юк.

Күптән түгел Фаяз Шәрип улы Хуҗинны Габдулла Тукай исемендәге дәүләт бүләгенә дәгъва кылучылар исемлегендә күреп, бик шатландым. Ул аңа һичшиксез лаек дип саныйм. Чөнки ул – коеп куйган галим генә түгел, борынгы мирасыбызны саклаучы һәм аны халык арасында актив пропагандалаучы да.

Гамирҗан ДӘҮЛӘТШИН

Алимент турында 7 сорау

Бала көтә... Әти дә юк, акча да

Ир белән хатын аерылышкач, таякның авыр башы балага төшә. Әнисе белән калса, этиләр никтер түләргә тиешле акчасын хатынына бирергә атлыгып тормый. Шуңа быелдан алимент түләмәүчеләргә җәзалар каттыйланды. Хәзер аларны мәҗбүри эшләтергә дә, кирәк икән, ирегеннән азат итәргә дә мөмкиннәр.

Алимент түләү хакында Россия Суд приставлары федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе сорау алуны оештыру бүлеге башлыгы Рамил ШИҺАПОВ белән сөйләштек.

:: Татарстанда бүген алимент түләмәүчеләр күпме?
– Хәзерге вакытта суд приставлары карамагында алимент түләттерү турында 19 мең 950 эш бар. Алимент түләмәүчеләр арасында, нигездә, ир-атлар, әмма әни кешеләр дә юк түгел: алимент түләмәүчеләрнең 13 проценты – хатын-кыз, 87 проценты – ир-атлар.

:: Узган елда суд приставлары тарафыннан алиментка бәйле нинди эшләр башкарылды?
– 2021 елдагы эшчәнлек нәтиҗәләре буенча 561 млн сум алимент түләттерелде, бу күрсәткеч 2020 елда түләттерелгән алиментлар суммасын 234 млн сумга арттырып җибәрде. Бурычы булган кешеләрне еш кына эзләтергә туры килә. Андый кеше теркәлгән урыны буенча яшәмәгән очраклар бар. Туганнары аның кайда яшәгәнлеген белмиләр, яисә бу мәгълүматны яшерәләр. Узган ел эзләтү чаралары нәтиҗәсендә алимент түләмәүче 850 кеше табылды һәм алар административ һәм җинаять җаваплылыгына тартылды. Ул кешеләрнең бер өлеше балаларына алимент түли башлады инде. Әгәр дә ел дәвамында алимент түләргә тиешле кеше турында бернинди дә белешмәләр булмаса, аны билгесез юкка чыккан дип тануны сорап, судка мөрәҗәгать итә ала. Бу очракта бала туендыручысын югалту буенча пенсия алырга хокуклы.

:: Алимент түләмәүчеләргә нинди җәза каралган?
– Балигълык яшенә җитмәгән балаларын карарга тиешле затларга карата моңа мәҗбүр итү кебек чаралар кулланырга туры килә. Андыйларны административ һәм җинаять җаваплылыгына тарту үз нәтиҗәсен күрсәтә. Әйтик, узган ел суд приставлары тарафыннан Административ хокук бозулар турында РФ кодексының 5.35.1 статьясы буенча 2 мең 957 административ беркетмә төзелде. Алимент түләүдән качып йөргән 1 мең 103 кешегә карата РФ Җинаять кодексының 157 статьясы буенча җинаять эшләре кузгатылды. Шунысын да билгеләп үтәм: быел 10 гыйнвардан башлап законнардагы үзгәрешләр үз көченә керде, алар нигезендә балаларын һәм хезмәткә сәләтле булмаган ата-анасын карау өчен өлешчә генә акча түләгән очракта да, алимент түләмәүче кешеләр административ һәм җинаять җаваплылыгына тартыла. Элек исә гражданнар «суд карарын яисә нотариаль яктан расланган килешүне бозып, балаларны карап тоту өчен нигезсез акча түләмәгән» очракта гына административ һәм җинаять җаваплылыкларына тартыла иде. Шул рәвешле, башкару документында билгеләнгән күләменнән киметеп, алимент акчасын өлешчә генә түләп килүче кешеләр дә, бурычларын үтәп баручы буларак, җаваплылыктан котылып кала ала иде.

:: Алимент акчасын тагын ничек итеп түләтеп була?
– Төрле чаралар кулланабыз. Андыйларның бурычны түләү хисабына шәхси мөлкәте алына һәм аңа арест салына, шулай ук банк счетларына арест салына, акчалары хезмәт хакыннан тотып калына, күчемсез мөлкәтне теркәтүне тыябыз, Россиядән читкә чыгып китү хокукын чиклибез, махсус хокуктан файдалануны (транспорт чараларын идарә итү хокукын) чиклибез, административ һәм җинаять җаваплылыгына тартабыз.

Алимент түләмәүче 10,4 мең кеше ял итү яки эш сәфәре буенча чит илгә чыга алмый. 2 меңгә якын кеше бурычларын түләп бетергәнгә кадәр машинасыннан файдалана алмаячак. Нинди дә булса чикләү кертү өчен, бурычлы кешенең мөлкәте булырга тиеш. Башкару эшчәнлеге кузгатылган очракта суд приставы-башкаручысы бурычлы затның мөлкәтен ачыклау өчен гаризалар юллый, ягъни аңа караган мөлкәт, аның эш урыны, мөлкәт рәвешендәге хокуклары буенча белешмәләрне сората.

:: Әгәр бурычлы кешенең эше дә (әйтик, рәсми эше), мөлкәте дә булмаса?
– Бурычлы кеше эшкә урнашмаган икән, ул Мәшгульлек үзәгенә исәпкә баса һәм пособие алып, алимент түли ала. Әгәр андый кеше алимент түләү өчен бернинди дә чаралар күрми икән, аңа карата Административ хокук бозулар турында РФ кодексының 5.35.1 статьясы буенча беркетмә төзелә. Бу статья буенча 150 сәгатькә кадәр мәҗбүри эшләр яисә 10 тәүлектән 15 тәүлеккә кадәр административ арест рәвешендә җәза күздә тотыла. Административ җаваплылыкка тартылган бурычлы затларның яртысы алиментларын түләргә керешә. Ә инде административ җаваплылыкка тартканнан соң да андый кеше алиментларын түли башламаса, суд приставы бурычлы затны РФ Җинаять кодексының 157 статьясы буенча җинаять җаваплылыгына тарту буенча чаралар күрә. РФ Җинаять кодексының 157 статьясында каралган җәза ул – бер елга кадәр төзәтү эшләре яисә мәҗбүри эшләр, 3 айга кадәр арест яисә бер елга кадәр иректән мәхрүм итү рәвешендә булырга мөмкин.

:: Алимент суммасы ничек исәпләнә?
– Алимент түләү турында килешү булмаса, балигъ булмаган балаларга алимент суд тарафыннан ай саен бер балага – ата яисә ана кеше ала торган хезмәт хакының һәм (яки) башка төрле керемнәрнең дүрттән бер өлеше күләмендә, ике балага – өчтән бер өлеше күләмендә, өч һәм аннан күбрәк балага яртысы күләмендә түләнелә. Әгәр балигълык яшенә җитмәгән бала өчен алимент түләргә тиешле кешенең даими эш урыны яисә керемнәре булмаса, ул вакытта түләнергә тиешле алимент күләме Россиядә билгеләнгән уртача хезмәт хакы күләменә карап билгеләнә.

:: Документ суд приставларына үтәү өчен әле генә килеп кергән икән, бурыч каян барлыкка килергә мөмкин соң?
– Башкару документында бурычлы кешенең алиментларны кайсы көннән башлап түләргә тиешлеге күрсәтелә. Әгәр алимент түләттерүче кеше гаризада билгеле бер чорда алиментлар алмавын күрсәтә икән, суд приставы-башкаручысы бурыч күләмен исәпләп чыгара һәм якларга: бурычы булган затка һәм акча түләттерүчегә тиешле карарны җибәрә. Документны җиткерер алдыннан бурычлар түләнмәгән чорны иң күбе 3 ел өчен күрсәтеп була, законнарда шулай билгеләнгән.

Гөлгенә ШИҺАПОВА әзерләде

ӘНИЕМ... ӘНИКӘЕМ...

Язучы сүзе

Зираттан кайтып киләм. Берни дә уйлап булмый, хис-тойгылар аңны томалаган. «И әнием... – дим дә тирән көрсенеп өстәп куям, – Әникәем...»

Бүген җиденче көне булса да, фани дөньядан китүен, аның мәңгегә дә кире кайтмаячагын яңа гына чамалый башладым бугай. Ләхеткә төшергән чак күз алдына килә. Кәфеннең очларын сүтеп, башын кырынрак каратып куйган чак. Ни өчендер әни ул вакытта сабый бала шикелле тоелган иде. Шундый җиңел, назлы. Безнең тормышка биреп бетерелмәгән нурлары ак кәфен аша сирпелеп торган сыман. Исән чагында да, соңгы атналарында, мин аны бала кебегрәк итеп күрдем: «Алар безне бала чагыбызда тәрбияләп үстергән, шушы тормышка әзерләгән, ә хәзер үзләре бала хәлендә, хәзер без аларны тәрбия кылып, бүтән тормышка әзерлибез. Шулай тиеш». Кабергә төшергәндә дә бала сыман тоелуы, бәлки, шунлыктандыр. Бер карасаң, чынлап та шулайдыр инде ул. Фанилыктан киткәч, кеше теге дөньяга сабый бала булып барадыр.

– Әнием...

Бу сүзләрнең кайтавазы күңелнең бөтен почмакларына бәрелеп кабатлана. Югалту, юксыну, үкенү хисләре җанны кырып алгандай тоела. Кайдандыр күтәрелгән кайнар дулкын бөтен барлыгыңны тетрәндерә. Бер мизгелгә бөтен буыннар йомшарып китә. Калтыранган бармаклар керфек очларына кунып дерелдәгән күз яшьләрен сөртеп ала. Үксеп елап җибәрүдән тыелырга тырышып, тешләреңне кысарга мәҗбүр буласың...

Хисләр уйнавы югалту хисеннән генә түгел. Бер карасаң, аның яше дә зур иде инде. Авырту-сызланулары да чамасыз һәм ул үзенә күп калмаганлыгын яхшы белә иде. Мин дә белә идем. Бертуктаусыз «әй, Аллакаем!..» дип ыңгырашып, үрсәләнеп

ятуларын уйласаң, кайгырырга түгел, ә «котылды» дип шөкер итәргә дә буладыр. Буладыр. Ул ныграк авырып киткән чакларда мин үземнең Казанда калуымнан курка идем. Ул үлеп китәр дә янына керүче табылмас, өйдә исләнеп ятар кебек тоела иде. Алай булмады. Әле үзем, әле хатыным, әле туганнарыбыз даими рәвештә карап, тәрбияләп тордык. Гомеренең соңгы вакытлары гел кадер-хөрмәттә узды. Үзе дә рәхмәтләрен укып, якты теләкләрен теләп китте.

Тик барыбер үкенечләр кала... Үлем үкенечсез булмый икән. Сызланулары бик көчәя башлагач, «ашыгыч ярдәм» машинасы белән хастаханәгә алып киттем. Үзе башта карышты: «Бармыйм. Миңа вакыт җитте инде», – диде. Шуннан эндәшмәде. Мин дә башта: «Әллә интектереп йөрмим генә микән соң?» – дип уйладым. Тик бу үлем килгәнен көтеп яту кебек күренде. Нәрсәдер эшләргә кирәк иде. Хастаханәдә гомер өстәмәгәннәрен белсәм дә, анда барса, хәле бераз җиңеләер, бәлки әле ныгып та китәр шикелле тоелды. Әйбәт карадылар. Ыңгырашулары басылды, соңгы вакытта беренче тапкыр тынычлап йоклап китте. Аякларындагы зәңгәрсу таплар таралып, тәненә җылы керде. Минем күңелдә өмет кабынды. Ныгып китүенә ышаныч артты. Табиблар су эчермәскә кушкан иде. Ә әни уянып китә дә су сорый. Салкын су. Тавышлары карлыккан инде. Салкын су бирсәм, тамагы шешәр кебек тоела. Мин юеш чүпрәк белән иреннәрен генә чылатам, я калак очы белән генә җылымса су каптырам. Ә аның эчәсе килә. Чынаяклап. Тик алай ярамый. Һәм мин калак белән генә... Хәзер уйлыйм менә: «Эчерергә кирәк булган икән. Эчләре янгандыр инде, шуларны салкын су белән басарга теләгәндер. Тик мин генә аңлап җитмәгәнмен...» Их... Могҗизага өметем зур иде шул. Аның ныгып китүенә ышанычым бар иде. Мин аны аз гына булса да тагын яшәтергә тели идем... Ә болай... Соңгы көннәрендә су да җәлләгән кебек килеп чыкты...

Әмма җанны кырган үкенечләрнең иң зурысы бу түгел әле.

Менә мин зираттан кайтып киләм. Тел очында бер сүз мең төсмерләргә кереп кабатлана:

– Әнием... Әникәем...

Ә үзе исән чакта мин аңа беркайчан да «Әнием» дип тә, «Әникәем» дип тә әйтмәдем. Ул минем өчен һәрвакыт «Әни» генә. Ул минем өчен әти урынына да, әни урынына да иде. Шуңа һәрвакыт бераз кырысрак, таләпчәнрәк булды. Бер-беребезгә төче сүзләр әйтешмәдек. Аралашу шаяру, беркадәр төрттерү аша булды. Үзенең дә «улкаем» дип әйткән чаклары бары тик мин бик авыр хәлгә калган яки чирләп киткән чакларда гына иде бугай. Соңгы көннәрендә әйткәләде. Төннәрен: «Улкаем!» – дип уятты. «Улкаем, су гына бир әле...» «Улкаем, торып утырыйм әле...» Тик мин шунда да әнием дип әйтмәдем. Китәчәген белгән вакытта да: «Болай дип әйтсәм, сискәндерермен, яшәүгә өметен өзәрмен», – дип тыелып калдым. Әйтергә кирәк булган.

Кадерле кешеләреңә үзләренең кадерле икәнлекләрен һәрдаим сиздереп торырга, якты хисләреңне, матур сүзләреңне кызганмаска кирәк икән. Гомер дә берәү генә, кадерле кешеләребез дә артык күп түгел бит инде. Ә сүзләр күп. Хисләр күңел тулы. Якты хисләреңне күрсәтүдән дөнья яктырып кына китә. Кояш якты нурын сипкән шикелле, бәлки, кешеләр дә үзләренең якты хис-тойгыларын сибеп яшәргә тиешледер. Кем белә инде...

Ә минем күңелнең иң төбеннән ургылып чыккан иң кадерле кешемә юнәлтелгән сүзләр фани дөнья буйлап адашып йөри. Барып җитәлмәгән хат шикелле. Шулай бар дөньяны әйләнеп чыгалар да кая барып бәрелергә белмичә, үз җаныма килеп кадалалар. Хәзер ул сүзләр дә ятим инде:

– Әнием... Әникәем...

Марат КӘБИРОВ

«НӘНИ ГЕРОЙ»

Язмышлар ярында

Дәвалаучы табибы, Балтач кызы Ясминә Гозәерованың сабырлыгына сокланып, әнә шулай ди. Өрлек кадәр ир-ат соклансын өчен, ун яшьлек авыру балада нинди сабырлык булу кирәктер – чамалау кыен түгел. Дәвалау курсын тырышып үткәне өчен мактау кәгазенә кадәр бүләк итә ул аңа. Мондый курслар, дәваланулар, авыр күнегүләр аша әллә ничә кабат үткән шул инде бу сабый.

Барган бер җирдә үзен шулай яратып, сокланып калалар. Аякка бик тә басасы, бик тә йөрисе килә балакайның. Сабыр итүе, барлык авырлыкларга түзүе, өйдә даими шөгыльләнүләре дә шуның өчен. Туганнары, танышлары матур күлмәк, уенчык, тәм-том алырсыз дип биргән акчаларны да тизрәк әнисенә бирергә ашыга кыз: «Дәвалануга барырга тотарбыз...»

Күңеле белән һич тә авыру бала димәссең Ясминәне. Кешеләрне бик ярата, гел көлеп, елмаеп кына тора. Өйләренә кунак килгәнгә дә шатлана, үзе дә каядыр барырга әзер тора. Бу кадәресе – әти-әнисенең аны кечкенәдән дүрт стена арасына бикләмәве нәтиҗәседер дә. Мөмкинлекләре чикле балалар өчен үткәрелгән бөтен чараларга баралар, бергәләп табигатькә чыгалар, коляска белән көн саен урамда йөриләр, өйдә торып укыса да, сыйныфта үткәрелгән барлык чараларда катнашалар. Сыйныфташлары да, башка укучылар да өйләренә әле хәлен белергә, әле концерт куярга килә. Ул үзе дә шигырь сөйләргә, кушылып җырларга, үзенчә биергә ярата. Социаль челтәрләрдә үткәрелгән, онлайн барган конкурсларда катнашып, җиңүләр дә яулаган инде Ясминә.

Әнисе Айгөлне сабый чагыннан беләм. Заманында бертуган апамнар белән бер йортта, күршеләр булып яшәделәр, балалары белән бергә үстеләр, укыдылар, тормышка чыктылар... Ясминә – Айгөлләрнең икенче кызлары. Өлкәне Сылуга – 14 яшь, исеме җисеменә туры килә торган, бик мөлаем, һәр яктан уңган-булган кыз булып үсеп килә.

– Сылуны да иртә тапкан идем, ә Ясминәбез 29 атнадан ук туды, – дип искә ала ул көннәрне Айгөл. – Суым китеп, Балтач хастаханәсенә бардым, анда Казанга барырга куштылар...

Башкаланың беренче номерлы бала табу йортында, кызганычка, Айгөлне кочак җәеп каршы алмыйлар. Өч көн авырып, аңын җуеп егылгач кына чабыша башлый ак халатлылар. Менә шушы өч көндә бала күпне югалта: кислород кытлыгы белән туган бала, әнисе кайтып киткәч тә, шактый вакыт ДРКБда ята... Хастаханәдән кайтканда үтә дә кечкенә, үтә дә ябык булган Ясминә, тора-бара үсеп, тазарып китә. Тик бу чордагы авырлыклар үтте дип тынычланасы урынга берничә айдан әти-әни күңеленә шик керә. Башын тиешенчә тотса да, кызларының утырып тора алмавыннан, аякларына баса алмавыннан куркып, алар табибтан табибка йөри. Тик, сүз берләшкәндәй, барысы да, җитлекми туу нәтиҗәсе, дип җавап бирә. «Без бит инде – җитлекми туган бала күргән кешеләр. Сылу белән Ясминәбезнең үз-үзләрен тотышы нык аерыла», – дип икеләнсәләр дә, әти-әнигә табиблар сүзенә ышанып, көтүдән башка чара калмый. Тик табибларның «балагыз вакытында тәпи китәчәк» дигән фаразлары чынга ашмый. Ике яшендә инде Ясминәгә ДЦП диагнозы куела.

Башта югалып калсалар да, Айгөл белән Ришат әнә шул көннән Ясминәнең киләчәге өчен чын мәгънәсендә көрәш башлый. Кайларга гына алып бармыйлар, нинди генә күнегүләр эшләтмиләр! Алтын куллы Ришат нинди генә җайланмалар ясамый... Ясминә кебек балалар өчен эшләнгән велосипед та сатып алалар, анда йөрергә өйрәтеп кенә калмыйлар, ярышларда катнашып, уңышлы чыгыш та ясыйлар. Кыскасы, бу гаиләдә әти дә, әни дә бер дәрәҗәдә кызларының иң олы хыялы чынга ашсын өчен кулдан килгәнне дә, килмәгәнне дә эшли. Ул мүкәләсә – мүкәли, ул күнегүләр ясаганда аңа кушыла. Бу тырышлыкларның нәтиҗәсе көннән-көн ачыграк күренә: Ясминәнең гәүдә тотышы ныгый, кеше ярдәме белән булса да аякларында шактый ышанычлы басып тора. «Ул үзенең йөри башлаячагына шулкадәр ышана, шулкадәр көтә», – ди Айгөл. Тырышлыкларың бушка китмәсен, уңышлар сиңа, «нәни герой»!

Гөлсинә ХӘБИБУЛЛИНА

P.S. Бу көннәрдә Гозәеровлар чираттагы тернәкләндерү курсларына барырга әзерләнә. 366 мең сум торучы бу курсларга тиешле сумма инде игелекле кешеләр ярдәме белән җыйналып беткән диярлек. Нибары 32 мең сум тирәсе генә җитми. Ярдәм итәргә теләүчеләр акчаны **4817 7602 5142 2642** номерлы Саклык банкы картасына күчерә ала. Ул шулай ук Айгөлнең телефон номерына да ялганган: 89172493920.

Баш мөхәррир –
САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 7066 данә
Гомуми тираж – 16091 данә

Газетага сертификат бирелде Заказ 246

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+